Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы

КАРАР

6 сентябрь 2023 ел №16

Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2023 елның 1 мартындагы 3 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2023 елның 26 гынйварындагы «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында»гы 1-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, 2013 елның 23 июнендәге «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы»гы 50-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2023 елның 1 мартындагы 3 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 8 пунктының 8.7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Мәнфәгатьләр конфликты ягы булган муниципаль хезмәткәрләргә мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу чаралары булмау муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүне китереп чыгара торган хокук бозу булып тора, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасының Бердәм муниципаль берәмлекләре Порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле

үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г. Дәүләтгәрәев